| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| --- | --- | --- |
| 22.10.2013 | | №617-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 10 июлендәге 382-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 22 октябрендәге 617-п номерлы боерыгы

Министрлыкның норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 10 июлендәге 382-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан туфраклар сыйфатының төбәк нормативларын билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:
6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүчегә нигезләнгән баш тарту хатын җибәрү вакыты 3 эш көненнән дә артмый.

Баш тарту турындагы карарга суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.».

2. Дәүләт экологик экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе (Р.А. Шәһидуллина) югарыда күрсәтелгән Тәртип нигезендә эшләр үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министрының беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров